ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 058 от 30.04. 2019 г.

Район Башлыгының 2014 елның 27 гыйнварында кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәне раслау турында» 008 нче санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын һәм муниципаль хокукый актларын кабул иткәндә һәм гамәлгә ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карары, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә иҗтимагый советлар оештыру турында» 2009 елның 16 апрелендәге семинар-киңәшмә резолюциясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумының 2010 елның 11 февралендәге 1-пп номерлы утырышы беркетмәсенең 5.1пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм граждан җәмгыяте институтларының үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, к а р а р б и р ә м :

1. Район Башлыгының 2014 елның 27 гыйнварында кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәгә» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлек «Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары» түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"Иҗтимагый совет үз вәкаләтләре чикләрендә коррупциягә каршы эшчәнлек буенча түбәндәгеләрдә катнаша: